Шәехова А. З. Бөек җиңү кайтавазы [Бөек Ватан сугышының 80 еллыгына әдәби- музыкаль кичә] / А. Шәехова // Ачык дәрес. – 2025. – №5. – Б. 7-9.



айкый торган композитор да. Кызым Лилиягә әниләргә багышланган җырын биргән иде, беренче тыңлаганда да ук еладым. Гөлназ иҗатта да, шәхси тормышында да бәхетле булсын иде» ди - Татарстанның атказанган артисткасы Гөлдания Хәйруллина.

**1 алып баручы:** Моң нечкәртә икән күңелләрне
Һәм елата икән, җырлата.
Сагыну илләренә озата да
Сөелү иңнәрендә сызлата.
Моң дәвалый икән күңелләрне:
Сихәт бирә, искә төшерә.
Яшәүләре авыр булыр иде
Моң булмаса җирдә кешегә.

**2 алып баручы:** Кеше гомерләре юллар кебек,
Җырлар кебек кеше язмышы.
Куандыра шатлыклары,
Үкендерә ялгышы.
Җырлыйк әле, дуслар, җырлыйк әле,
Кайгы-хәсрәтләрне таратып.
Моңга чорнап дөньяларны,
Нурга чорнап, яратып.

Гөлназ, безнең тамашачыларга синнән матур җыр. (Кичә җырчы чыгышы белән дәвам итә)

**1 алып баручы:** Җыр – татар халкының иң таралган, иң хөрмәтле иҗат җимеше. Җыр сөйләр өчен түгел, ә көйләр өчен чыгарыла. Әгәр халыкның моңлы, аһәнле матур көйләре аның тиңдәшсез һәм оста композитор булуы турында сөйләсәләр, шул көйләрнең нәфис сүзләре аның акыллы һәм талантлы шагыйрь булуын раслый.

Җырларым – утлы учакмы,
Очкыннар чәчеп тора.
Яну һәм сүнү бәхетен
Җаның белән генә үрел,
Яктысын тоя – тоя.
Җырларым нигәдер бүген
Йөрәккә очкын коя....

**2 алып баручы:** Бүгенге җылы кичәбез ахырына якынлашты. Кунагыбыз җырчы һәм композитор Гөлназ Закировага иҗади уңышлар телибез. Яңа җырлары белән тамашачыларны сөендерүен дәвам итсен.

**1 алып баручы:** Игътибарыгыз өчен рәхмәт!

# БӨЕК ҖИҢҮ КАЙТАВАЗЫ

**Шәехова Алмазия Зиннур кызы**
Яр Чаллы шәһәре 12 нче китапханә

Бөек Ватан сугышының 80 еллыгына багышланган әдәби-музыкаль кичә

**Алып баручы:** Мәңгелек ут яна. Шул утларда
Күпме язмыш яна, күпме яра.
Киләчәккә имин барыр өчен,
Үткәннәргә бер борылып кара.

Хәерле көн, укучылар! Һәр яңа көн туды исә, без бер-беребезгә имин, тыныч көннәр телибез. Мин дә менә сезгә: «Хәерле көн!» — дип эндәшәм. Узган һәрбер көнебез, кылган барлык гамәлебез хәерлегә булсын. Көннәр, еллар бер-бер артлы үтә тора. Алда Бөек Җиңүнең 80 еллыгы. Бәйрәмнәрнең иң олысы, иң кадерлесе - әлбәттә, Җиңү бәйрәме.

Күп корбаннар хакына, зур югалтулар бәрабәренә яуланган Җиңү ул! Тарих бу кадәр булган афәтне башка хәтерләми. Рәсми мәгълүматларга караганда, илебез бу сугышта 27 млн кешесен югалткан, 1700 шәһәр хәрабәгә әйләнгән, 10 мең авыл җир белән тигезләнгән. Димәк, анда яшәүчеләрнең ачы язмышын күзалларга була.

1941 нче елның 22нче июнь таңы. Гүзәл авыллар, шәһәрләр татлы йокыда. Шул вакытта немец фашистлары илебез чикләрен бозып кереп, авылларны, шәһәрләрне утка тоталар. Бөек Ватан сугышы башлана.

Үткән гомер — аккан су, искән җил, диләр. Ә менә Бөек Ватан сугышының данлы үткәне аның үлемсез каһарманнары без бервакытта да истән чыгарырга хаклы түгел. Һ.Такташның «Киләчәккә хатлар» әсәрен күпләрегез хәтерлидер :анда түбәндәге юллар бар:

Сез бу хатны минем укыганда,
Мин бик күптән үлгән булырмын,
Еллар бер-бер артлы үткән булыр,
Исемем сезгә җитмәс — онытылыр...

Әйе, «Исемем сезгә җитмәс — онытылыр», — ди шагыйрь. Шөкер Һ.Такташның кем икәне билгеле, аның бөек шагыйрь икәнен онытмадык.

Сезненчә, 1418 көн, 1418 төн буена барган сугыш кайтавазы, җиңелүләр, җиңүләр, югалтулар, батырлыклар онытылырга тиешме? Киләчәк буыннарга бу көннәр, вакыйгалар турында житкерә алырбызмы соң?

**1 укучы:** Тын-тын дала.
Моннан сугыш үткән.
Кан коелган монда,
Кан аккан.
Тәмуг кебек ялкын дөрләп янган,

Утлы телен сузып һәр яктан.
Көн тумаган.
Ялкын ут эчендә
Җир белән күк гүя тоташкан.
Җирләр тетрәп,
Күкләр күкрәп торган
Туплар улавыннан тоташтан.
Бүген тып-тын.
Бөтен тирә-якта
Тибрәнә тик сары кылганнар.
Күпме ирләр монда тынлык саклап,
Мәңгелеккә тынып калганнар. (Р.Вәлиева)

Илебезгә һөҗүм иткән дошман бик көчле һәм рәхимсез була. «Һәр очраган совет кешесен үтер, синең алдыңда карт кешеме, хатын-кызмы, ир баламы, туктап калма — барысын да үтер», — дип язылган була фашистлар боерыгында. Һәм фашистлар үтерә. Алар миллионнарча совет кешесен: коралсыз, көчсез, авыру кешеләрне юк иттә, картларны, хатын-кызларны, балаларны газаплый һәм үтерә. Фашистлар узган һәр җирдә үтерелгән кешеләр, яндырылган, җимерелгән шәһәрләр һәм авыллар калда. Фашистлар совет кешеләрен куркытырга, аларны карусыз колларга әйләндерергә тели.

Татарстан кешеләре фронтның һәрбер участогында сугышалар, зур батырлыклар күрсәтәләр. Бөек Ватан сугышы елларында 174 мең якташыбыз орден һәм медальләр белән бүләкләнгән. Батырларның да батырларына бөек исем - Советлар Союзы Герое исеме бирелә. Республикабызда туып-үскән 170 тән артык кеше шушы зур исемгә лаек була. Хәзер сез концлагерьда да фашизмга каршы көрәшен туктатмаган, батырларча һәлак булган җәлилчеләрнең берсе - А.Алишның - тоткынлыкта язган шигырен ишетерсез.

**2 укучы:** Әйтсәләр дә: барып тор син, дип,
Дөньяның иң рәхәт җиренә,
Әйтер идем: кирәк түгел, дип,
Кайтам мин, дип, туган илемә.
Әйтсәләр дә: алтын сарайда тор син,
Ләкин илең ирексез калсын, дип,
Әйтер идем: мине зинданга сал,
Фәкать илем ирекле булсын, дип.
Сатмас егет илен алтын-көмешләргә,
Әгәр югалтмаса вөҗданын;
Алтынны ул чүпкә санар,
Иң кыйммәтле күрер Ватанын.

Бөек Ватан сугышында совет халкы үзенең 27 млн улын һәм кызын югалтты, шуларның 320 мене - безнең якташларыбыз - моны һич кенә дә онытырга мөмкин түгел. Ышанып әйтергә була, илебезнең намусы, азатлыгы, анда яшәүче күпмилләтле халыкларның бәхете өчен гомерләрен биргән ватандашларыбызның истәлеген кадерләп сакламаган бер генә дә гаилә юк бездә. Чөнки бу - һәлак булучыларның гына түгел, ә безнең дә фаҗига, балаларын югалткан хатыннар фаҗигасе, әти-әнисез үсүче балалар фаҗигасе, кыскасы, ил күләмендәге фаҗига .

Җиңү безнең туган якларга һәм дусларыбыз илләренә иминлек, азатлык, тыныч хезмәт язының иркен сулышын алып килде.

(Муса Җәлилнең «Ана бәйрәме» шигыре укыла.)

**Алып баручы:** Хатын-кыз һәм сугыш. Болар - бер-берсенә ят төшенчәләр, аларны янәшә куеп, үзара бәйләнештә әйтүе сәер. Ләкин без илебез тарихыннан үз Ватаныбыз иминлеген саклап яуга күтәрелгән, тылны икенче фронт итеп, армый-талмый эшләгән хатын-кызларның исемнәрен әйтә алабыз. Сугыш елларында колхозны алып барган, фронтны азык-төлек, кием-салым һ. б. кирәк-яраклар белән тәэмин итүдә актив катнашкан әбиләр, әниләр, апалар, балалар...

Кемнәр соң алар Ватаныбызны яклап яу кырына киткән хатын-кызлар? Бөек Җиңүне яулап алу хакына күрсәткән батырлыкларыгыз халкыбыз күңелендә мәңге сакланыр!

Бөек Җиңү сугыш кырларында гына яуланмады. Татарстан кызлары яуга киткән биш йөз меңнән артык ир-атны алыштырды. Хатын-кызлар сабан сөрде, чәчте, урды, туплар һәм ядрәләр, самолетлар ясады, шинельләр текте. Ашлык басуы һәм завод цехы алар өчен сугыш кырына әверелде. Алар фронтны алты йөзгә якын төрдәге техника, корал, сугыш кирәк-яраклары, азык-төлек, кием-салым белән тәэмин итеп торды.

Авыр сугыш елларының ачысын-төчесен барыбыздан да күбрәк татыган, җиңү сәгатен якынайту өчен, тиңдәшсез хезмәт батырлыклары күрсәткән фидакарь аналарга дан һәм хөрмәт!

Көтә ана.
Аның чәчләрендә
Көмеш микән,
Әллә кар микән?
Батырларга Җирдә һәйкәлләр бар,
Көткәннәргә һәйкәл бар микән?

Әйе, хатын-кызларның сабырлыгын, ныклыгын, түземлелеген сугыш аяусыз сынады. Алар, моңарчы ирләр күтәреп барган авыр хезмәтне үз

иңнәренә алды. Ирләр өчен дә, үзләре өчен дә бар көчләрен биреп эшләде, ятим калган балаларны тәрбияләде. Кыскасы, сугыш чорында, хатын-кыз искиткеч бөек көч була.

2001 нче елда Татарстанда нәшер ителгән сугыш китергән хәсрәт-михнәт дәрьясын соңгы тамчысына хәтле эчеп, өсләренә ишелгән бөтен авырлыкларга чыдап-түзеп, ил-көн өчен сәламәтлекләрен, яшьлекләрен, бәхетләрен корбан итеп, париканатсыз калган газиз жаннар-кыз-әбиләргә багышланган китап. ("Кыз-әбиләр" китабыннан 2 бит укырга)

Илебездә аналар батырлыгын мәңгеләштерү өчен һәйкәлләр салынган. Мәсәлән, Мамай курганында мәһабәт Ватан-ана скульптурасы тора. Кулына кылыч тоткан Ватан-ана үзенең улларын һәрчак уяу булырга чакыра. Ана: «Яулап алынган тынычлыкның кадерен белегез», - дип эндәшә сыман.

Фашизмга каршы көрәштә батырларча һәлак булган биш бертуган Куприяновлар һәм аларны тәрбияләп үстергән ана истәлегенә Белоруссиянең Жодино шәһәрендә мәһабәт монумент куелган. Өлкән яшьтәге гади генә хатын-кыз - бусагага - кечкенә генә пьедесталга баскан. Каршында аның улларын үлемсезлеккә алып киткән юл. Батыр егетләр, кызу-кызу атлап, яуга китеп бара.

Туган Татарстаныбызда да аналар истәлегенә салынган һәйкәл бар. Мамадыш шәһәре үзәгендәге «Хәтер» паркында яу кырларында үзенең газиз сигез баласын югалткан Анага һәйкәл куелган. Мәһабәт ап-ак һәйкәлдә Фатыйха апа Әхмәдиева (тумышы белән Мамадыш төбәгенең Урта Кирмән авылыннан) образы гәүдәләнгән.

Бер үк вакытта бу һәйкәл яу кырларында улларын, кызларын, ирләрен, туганнарын, якыннарын югалткан барлык Аналарга, җиңү таңын якынайткан тыл батырларына тирән хөрмәт, аларның олы кайгысын уртаклашу билгесе дә.

Бөек Ватан сугышы бик күп гаиләләрне кайгы-сагышлы итте. Бүген без аларга исемләнгән теләктәшлек сүзләрен тагын-тагын кабатлыйбыз. Әйе, зур югалтулар кичерелгән, аларны сүз белән аңлатып та, үлчәү белән үлчәп тә, оныттырып та булмый. Ләкин барыгыз да шуны белегез, шуны онытмагыз, хөрмәтле укучылар, сугыш корбаннары турында үлемсез хатирә халык күңелендә мәңге сакланыр! Бөек француз әдибе Виктор Гюго әйткәнчә, Ватан ярасы әрнүен безнен һәркайсыбыз үз йөрәгендә сизә бит! Сезнен кайгы - безнең кайгы ул. Җиңүчеләр каны юкка түгелмәде.

Сугыш ул - коточкыч фаҗига. Аның бер көнен күз алдына китергәч, йөрәкләр жу итә.

Батыр сугышчының үз гомерләре бәрабәренә батырлык эшләргә нәрсә мәжбүр иткән соң?

Алар үз илләренең патриотлары булган. Патриот булу - кирәк булганда үз гомерение дә кызганмыйча туган жирне саклау ул.

Сугышчылар - Ватанны күз карасыдай сакларга дип хәрби ант биргән кешеләр алар. «Ватан» сүзе «ана» сүзе белән янәшә куелган, шуңа да «Ватан-ана чакыра!» лозунгы төп чакыру авазы булган.

"Тынычлык" М.Садри шигыре.

Без телибез ак күгәрченнәрнең
Зәңгәр күктә биек очуын.
Без телибез сабый балаларның
Кайгы хәсрәт күрми үсүен.
Тынычлык, иминлек, чын дуслык ул,
Халыкларның изге теләге,
Тынычлык, тынычлык, тынычлык дип,
Миллионнарның тибә йөрәге.
Тынычлык ул - алтын бодайларның,
Амбарларда тулып агуы,
Тынычлык ул безнең илебездә,
Хыялларның чынга ашуы.

Әйе, һәр кеше күңелендә бер теләк: илләр имин булсын иде, сугыш утлары кабынмасын, кешеләрнең гомерләре өзелмәсен, толлар һәм ятимнәр күз яше түгелмәсен иде!